**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 26.03.2021** **№ 324**

## Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым бурычын каплау эшен оештыру турында» 2020 елның 30 декабрендәге 16-54/16211 номерлы мәгълүмат хатын, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «МНПАга үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 гыйнварындагы 09/13-09/49 номерлы соратуын, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында норма кертергә кирәкле муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм процедурасын регламентлаштыра торган муниципаль норматив хокукый актлар исемлеген җибәрү турында» 2021 елның 19 гыйнварындагы 11/13-09/140 номерлы мәгълүмат хатын, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Салым бурычын каплау эшен оештыру турында» 2021 елның 26 гыйнварындагы 05-51/399 номерлы соратуын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортны) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезләмәләре электрон формада «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше нигезендә расланган дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен электрон формада күрсәтүгә күчүнең план-графигы белән билгеләнгән срокларда кулланыла дип билгеләргә.

3. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 30 мартындагы 810 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының административ-техник инспекциясе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча

хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021
елның 26 мартындагы 324
номерлы карары белән

**Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының административ-техник инспекциясе» муниципаль казна учреждениеесе (алга таба - Учреждение).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Биектау районы, Биектау т/юл.ст.пос., Кооперативная ур., 5 й.;

Учреждениенең урнашкан урыны: Биектау районы, Биектау т/юл.ст.пос., Профсоюз ур., 1а й.;

Учреждениенең эш графигы:

дүшәмбе – пәнҗешәмбе: 8.00 дән 17.00гә кадәр;

җомга: 8.00 дән 16.00 га кадәр;

кабул итү көннәре: сишәмбе, 14:00 тән 17:00гә кадәр

шимбә, якшәмбе - ял көннәре.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке тәртип кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә өчен телефон 8(84365)74-775.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре) муниципаль районның рәсми сайты адресы: (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында, шулай ук Учреждениенең урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет биналарында урнашкан гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы)

муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (http:// vysokaya-gora.tatarstan.ru).

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi. tatar.ru/) (алга таба – Региональ портал);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

5) Башкарма комитетта (Учреждениедә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яки телефон буенча;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон почта аша электрон формада.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Учреждение белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм Башкарма комитет биналарындагы мәгълүмат стендларында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (2001 елның 29 октябрендәге 44 номерлы РФ Законнар җыентыгы, 4147 ст.);

2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы «Техник җайга салу турында» Федераль закон (алга таба - 184-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 30.12.2002, №52 (1өл.), 5140 ст.),

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (2003 елның 6 октябрендәге 40 номерлы РФ Законнар җыентыгы, 3822 ст.);

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.);

Федераль казначылыкның 2012 елның 30 ноябрендәге 19н номерлы«Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасын алып бару тәртибен раслау турында» боерыгы (алга таба - 19н боерыгы) (федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары Бюллетене, №1, 07.01.2013);

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы (алга таба –45-ТР номерлы ТР Законы ) (Республика Татарстан, №155-156, 03.08.2004);

Биектау муниципаль районы Советының 2020 елның 19 октябрендәге 14 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы (алга таба - Устав);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 февралендәге 216 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы административ-техник инспекциясе» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

тышкы мәгълүмат чарасы (вывеска) - оешма урнашкан урында һәм (яисә) турыдан-туры товарны гамәлгә ашыру, хезмәт күрсәтүләр урынында урнашкан, мәгълүматны кулланучылар игътибарына җиткерү өчен биналарны мәгълүмати бизәү максатларында күрсәтелүе «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 9 статьясы нигезендә мәҗбүри булган мәгълүмати конструкция булып торучы территорияне төзекләндерү элементы, атап әйткәндә, оешманың фирма атамасы (исеме), аның урнашкан урыны (адресы) һәм аның эш режимы турындагы мәгълүматны, шулай ук закон таләбе буенча урнаштырылуы мәҗбүри булган яисә эшлекле әйләнеше гадәте аркасында урнашкан һәм реклама белән бәйле максатларны эзәрлекләми торган мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны - Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) шәһәр яки авыл җирлегендә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турындагы" 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза (алга таба - гариза) дигәндә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 статьясындагы 3 пункты (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла. Гариза стандарт бланкта (1 нче кушымта) тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү | Төзекләндерү кагыйдәләре |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеру органы исеме | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы административ-техник инспекциясе» муниципаль казна учреждениесе | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 февралендәге 216 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы административ-техник инспекциясе» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | 1) тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү;<br>2) тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерүдән баш тарту. | |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында | Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, гариза бирү көнен кертеп 10 көн[1]<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткән көнендә гамәлгә ашырыла. | |

[1]Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы суммар сроктан чыгып, административ процедураларны башкару өчен кирәкле минималь сроктан чыгып билгеләнде. Административ процедураларның дәвамлыгы эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| каралган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документларны бирү (җибәрү) срогы | Гаризада (почта яисә электрон адресы буенча) күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә җибәрү гамәлгә ашырыла | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1) гариза:<br>-кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (1 нче кушымта);<br>-Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон рәвештә;<br>2) шәхесне таныклаучы документлар;<br>3) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);<br>4) тышкы мәгълүмат чарасы (алга таба - СНИ) кушыла торган милекнең яисә мөлкәткә ия булу хокукын раслый торган документның таныкланган күчермәсе;<br>5) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып, милекченең яки тиешле күчемсез мөлкәтнең Россия Федерациясе ГрК 19 статьясындагы 5, 6, 7 өлешләрендә күрсәтелгән башка законлы хуҗасының әлеге мөлкәткә СНИ кушуга язмача яки электрон документ формасында ризалыгын раславы, әгәр мөрәҗәгать итүче күчемсез мөлкәтнең милекчесе яисә башка законлы хуҗасы булмаса. СНИны урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдалану кирәк булган очракта, әлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| | милекчеләрнең ризалыгын раслый торган документ булып күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы шул исәптән, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрелгән җыелышы беркетмәсе тора. Әгәр мөрәҗәгать итүче мондый ризалык алуны раслый торган документны үз, дәүләт милке яисә муниципаль милке буенча тапшырмаган булса, муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә шәһәр округының җирле үзидарә органы вәкаләтле органда мондый ризалык булу турында белешмәләр соратып ала.<br>Әгәр дә СНИны урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдалану кирәк булса, әлеге милекчеләрнең ризалыгын раслый торган документ булып күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының беркетмәсе тора;<br>6) Мөрәҗәгать итүченең биләгән бинага, урынга, стационар булмаган сәүдә объектына мөлкәти хокукларын раслый торган хокук билгеләүче документлар, алар СНИны урнаштыручы оешманың, индивидуаль эшкуарның урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булып торалар (дәүләт теркәве тиеш булмаган документлар булганда).<br>7) Әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә җир кишәрлегенә хокук, күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрында аның теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип танылса (күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | реестрында җир кишәрлегенә хокуклары турында белешмәләр булмаганда тапшырыла) (кирәк булганда), аерым торучы СНИ урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булган бина урнашкан җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукларын таныклаучы (билгели торган) документлар.<br>8) Рәсмиләштерелгән тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорт).<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетта шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакларда түбәндәге ысулларның берсе тарафыннан тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>- почта аша.<br>Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Региональ портал аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына буйсынулы оешмалар карамагында булган | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1. Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (юридик затлар өчен).<br>2. Шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (шәхси эшмәкәрләр өчен). | |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә башка оешмалар | 3. Мөрәҗәгать итүченең СНИны урнаштыра торган оешманың, индивидуаль эшкуарның урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булган бинага теркәлгән хокукын раслый торган документ (әгәр мондый документ дәүләт теркәве узарга тиеш булса).<br>4. Аерым торучы СНИ урнаштыручы оешманың, шәхси эшкуарның урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булган бина урнашкан җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукларын таныклаучы (билгели торган) документлар (җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмә Бердәм дәүләт реестрында күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш килешүләрендә булган очракта).<br>5. Бинаны арендалау шартнамәсе - күрсәтелгән документ Башкарма комитет тарафыннан бирелгән очракта.<br>6. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында Россия ФСХ белешмәләре.<br>Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүченең хезмәт күрсәтүдән баш тартуына нигез булып тормый | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1)Документларны тиешле булмаган зат тарафыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | тапшыру;<br>2)Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3)Гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген турыдан-туры аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди хилафлыклар булу;<br>4)Документларны тиешле органга тапшырмау | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән тышкы мәгълүмат чараларына карата таләпләргә СНИның туры килмәве;<br>2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат ачыклану.<br>3. Паспорты тәкъдим ителгән конструкция реклама конструкциясе билгеләренә ия.<br>4. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда нинди дә булса белешмәләрнең булмавы, укылмый торган текст, төгәл булмаган мәгълүмат.<br>5. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.<br>6. СНИда күрсәтелгән эшчәнлек яисә хезмәт күрсәтү төре гамәлдәге законнарга каршы килә | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләре | | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма күрсәтә торган хезмәт турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратның максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма күрсәтә торган хезмәт турында соратуын, шул исәптән электрон формада да теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.<br>Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратулар тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре куелган һәм һәрбер муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларга инвалидлар өчен үтемлелекне тәэмин итүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүе (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчеп йөрү) тәэмин ителә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү максатларында тәэмин ителә:<br>1) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып;<br>2) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясенең тотрыклы бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;<br>3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне аларның тормыш эшчәнлеген чикләүне исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;<br>4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләр һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-ноктала шрифты белән башкарылган билгеләр белән | Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | кабатлау;<br>5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемә кертү;<br>6) эт-озатучыны махсус укытуны раслаучы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Эт-озатучыны махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелүче документ булганда кертү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм әлеге пунктның 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркемгә мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>документлар кабул итү, бирү алып барыла торган бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашкан булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>Мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайтының мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу; | |

| | | |
|---|---|---|
| күләмдә) муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, җирле үзидарәнең башкарма күрсәтмә органы органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә, мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәтләрне 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган күпфункцияле үзәкләрдә (комплекслы сорату) берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату юлы белән муниципаль хезмәтне алу мөмкинлеге яки мөмкин түгеллеге | инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуда тоткарлыкларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮ ерак эш урыннарында консультация, документларны кабул итү һәм бирү белән КФҮ белгече шөгыльләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Биектау муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында, КФҮ дә алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы | |

| | | |
|---|---|---|
| | сорату составында муниципаль хезмәт күрсәтелми | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүче хокуклы:<br>а) Бердәм порталда яисә Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;<br>б) гаризаны электрон формасын тутыру юлы белән Республика порталының “Шәхси кабинет”ыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирергә.<br>Региональ порталның «Шәхси кабинет»ын кулланып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар җибәрелгәндә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланыла. Мөрәҗәгать итүче гади электрон имзаны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары белән каралган очракларда кулланырга хокуклы;<br>в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларның үтәлеше турында белешмәләр алырга;<br>г) Республика порталы ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;<br>д) муниципаль хезмәтне электрон документ рәвешендә күрсәтү нәтиҗәсен алырга;<br>е) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр | |

| | | |
|---|---|---|
| | (судтан тыш) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылган карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә шикаять бирергә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3)муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

3.2.1. Гариза бирүче Учреждениегә шәхсән үзе, телефон һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Учреждение белгече гариза бирүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителә торган документациянең составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат яисә КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача яки электрон рәвештә гариза бирә һәм документларны әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә Бүлеккә тапшыра.

Гаризаны электрон формада алганда, Учреждениенең гаризалар кабул итүгә җаваплы вазыйфаи заты:

а) электрон документлар әйләнеше системасында гаризаны теркәүне тәэмин итә, шул ук вакытта гаризаны «Ведомство тарафыннан кабул ителгән» яисә «Эшкәртүдә» статусы бирелә, бу Региональ порталның «Шәхси кабинетында» чагыла;

б) Бердәм порталга мөрәҗәгать итү юлы белән (мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон формалары тапшырылган очракта) электрон имзаның дөреслек шартлары үтәлешен тикшерә.

Әгәр көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның дөреслек шартлары үтәлмәү ачыкланмаган очракта, Учреждениенең вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза Бүлеккә кергән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, гаризаның кергәндәге теркәү номерын, гаризаны алу датасын, аңа беркетелгән документларның файллары исемлеген, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасын үз эченә алган гариза керү турында хәбәр җибәрә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның дөреслеге шартлары үтәлмәү ачыкланган очракта, Учреждениенең вазыйфаи заты:

электрон рәвештә кергән документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә;

мөрәҗәгать итүчегә электрон формада, 06.04.2011 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законның аны кабул итү өчен нигез булып торган 11 статьясы пунктларын күрсәтеп, кабул ителгән карар турында хәбәрнамә җибәрә. Мондый хәбәрнамә Учреждение вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 августындагы 852 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны куллану кагыйдәләренең 9 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән җибәрелә.

3.3.2. Гаризаларны кабул итүче Учреждение белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклау;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә белән эш йөртелсә);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда ассызыклаулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм килештерелмәгән башка төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, Учреждение белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

гариза бирүчегә тапшырылган документларның исемлеге күчермәсен бирү, анда муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын, бирелгән номерны, документларны кабул итү датасын күрсәтү;

гаризаны Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булган очракта, документларны кабул итүче Учреждение белгече гариза бирүчене гаризаны теркәүгә каршылыклар булуы турында кисәтә һәм, язма формада кабул итүгә каршы булуның сәбәпләрен аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гариза һәм документларны кабул итү вакыты - 15 минут;

гаризаны теркәү гариза тапшыру моментыннан бер көн эчендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Учреждение белгече электрон формада ведомствоара электрон үзара хезмәттәшлек системасы аша түбәндәгеләрне тапшыру турында соратулар җибәрә:

1. Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (юридик затлар өчен).

2. Шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (шәхси эшмәкәрләр өчен).

3. Мөрәҗәгать итүченең СНИны урнаштыра торган оешманың, индивидуаль эшкуарның урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булган бинага теркәлгән хокукын раслый торган документ (әгәр мондый документ дәүләт теркәве узарга тиеш булса).

4. Аерым торучы СНИ урнаштыручы оешманың, шәхси эшкуарның урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булган бина урнашкан җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукларын таныклаучы (билгели торган) документлар (җир кишәрлегенә хокуклар турында белешмә Бердәм дәүләт реестрында күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш килешүләрендә булган очракта).

5. Бинаны арендалау шартнамәсе - күрсәтелгән документ Башкарма комитет тарафыннан бирелгән очракта.

6. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында Россия ФСХ белешмәләре.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мәгълүмат белән тәэмин итүче(ләр) белгеч(ләр)е соратып алына торган документлар (мәгълүмат) тапшыралар яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында хәбәрнамәләр җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә).

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (белешмәләр) буенча өч эш көненнән артык түгел;

башка тәэмин итүчеләр буенча - ведомствоара сорату органга яисә оешмага кергән көннән алып биш көн эчендә, әгәр ведомствоара соратуга җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Учреждение белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризага кушымта итеп бирелә торган документлардагы белешмәләрне тикшерү;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Учреждение белгече СНИ урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектын (алга таба - Баш тарту турындагы карар) әзерли һәм әлеге Регламентның 3.5 п. каралган процедураларны башкара.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Учреждение белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре проектын әзерләү;

муниципаль хезмәт нәтиҗәсенең проектын (алга таба - Рөхсәт) килештерүгә җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар соратуларга җаваплар кергән вакыттан бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерүгә җибәрелгән Рөхсәт проекты яки бирүдән Баш тарту турындагы карар.

3.5.2. Килештерүче бүлекләр белгечләре алынган документларны карый һәм Бүлеккә килештерү турында бәяләмә яки килештерүдән дәлилләнгән баш тарту җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар килештерүче органнарның регламентлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Рөхсәтне килештерү турында бәяләмә яисә килештерүдән баш тарту.

3.5.3. Учреждение белгече, килештерүче органнардан документлар алып, Рөхсәтне яисә Баш тарту турында карарны Башкарма комитет җитәкчесенә имзага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзага җибәрелгән Рөхсәт яки Баш тарту турындагы карар.

3.5.4. Башкарма комитет җитәкчесе Рөхсәтне раслый яки Баш тарту турындагы карарны имзалый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган Рөхсәт кәгазе яки Баш тарту турындагы карар.

3.7. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.7.1. Учреждение белгече Рөхсәт яки Баш тарту турындагы карарны терки, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә. Мөрәҗәгать итүче килгәч, Рөхсәт кәгазен яисә Баш тарту турындагы карарны имза куйдырып бирә. Мөрәҗәгать итүче килмәгән очракта, почта аша, тапшырылуы турында хәбәр белән, заказлы хат җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче нәтиҗәне электрон рәвештә алу ысулын сайлаганда, мөрәҗәгать итүчегә электрон документ рәвешендә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

15 минут дәвамында - мөрәҗәгать итүче шәхсән килгән очракта;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү - имза салынган көндә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән яисә почта аша җибәрелгән Рөхсәт яисә Баш тарту турындагы карар.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза ( 3 нче кушымта);

гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия, техник хаталар булуын таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларда күрсәтелгән белешмәләрдә техник хаталарны төзәтү турында сорап язылган гаризаны гариза бирүче тарафыннан (вәкаләтле вәкил) шәхсән үзе, яки почта аша (шул исәптән электрон почтаны кулланып), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең Бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша тапшыра ала.

3.8.2. Документларны кабул итү буенча җаваплы белгеч техник хатаны төзәтүне сорап язылган гаризаны кабул итә, бирелгән документлар белән бергә терки һәм Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гаризаны теркәгән вакыттан бер көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Учреждение белгеченә каралуга җибәрелгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны тикшерә, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максаты белән гамәлдәге Регламентның 3.5 пункты белән каралган процедураларны башкара һәм төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) имза куйдырып тапшыра һәм гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен ала яки гариза бирүченең адресына почта аша (электрон почта аша) Бүлеккә техник хата булган документ нөсхәсен тапшырып, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылган яки кызыксыну белдергән заттан хата булу турында гариза кабул иткәннән соң өч көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклауны һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала .

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документларның проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүмат базасында булган белешмәләр, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче белгечләрнең телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка белешмәләр файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары, сәбәпләре турында белгечләр муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенә кичекмәстән хәбәр итәләр, шулай ук хокук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыруга җаваплы, шулай ук инфраструктур үсеш Учреждениесе белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр Законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аркылы тормышка ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларга, шулай ук аларның вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, хезмәткәрләргә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Учреждение хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) Башкарма комитетка яки муниципаль берәмлек Советына судка кадәр шикаять белдерү хокукына ия.

Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соратуны, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмуларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп, 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында каралмаган өстәмә документлар яки мәгълүмат яисә эшчәнлек таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнар, федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин;

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районы муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда

аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә 27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә27.07.2010 елның 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь чыганакта, электрон рәвештә Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы җирле үзидарәнең, йә гавами-хокукый берәмлекнең тиешле органына (алга таба - күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга тапшырыла. Башкарма комитет җитәкчесенең, яисә Башкарма комитетның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр муниципаль берәмлек Советына бирелә. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән вәкаләтле күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә вазыйфаи затка тапшырыла. Оешмалар хезмәткәрләренең 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.

Муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять кәгазь чыганакта яисә электрон рәвештә язма рәвештә бирелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы(http://www.gosuslugi.ru/), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак орган (ул булган очракта) кертелгән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуга яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге белешмәләрне үз эченә алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), яшәү урыны турында белешмә яисә гариза бирүче - юридик затның исеме, урнашкан урыны турында белешмә, гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәте күрсәтү органы, муниципаль хезмәте күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәвенә нигез булган гариза бирүченең дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләренраслый торган документлар (булган очракта) йә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тапшырган муниципаль хезмәтне алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган булса;
2) шикаятьне канәгатьләндерелүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.8. Шикаятьне әлеге регламентның 5.7 п. күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә карата канәгатьләнергә тиешле дип танылган очракта, Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк йә 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалар тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга кирәк булган алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне әлеге Регламентның 5.7 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавап белән канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлы аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат җиткерү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү, шул исәптән комплекслы ведомствоара сорату буенча;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә кулланылган мөрәҗәгать итүченең көчәйтелгән квалификация цифрлы электрон имзасының дөреслеген тикшерү;

5) Башкарма комитетка документлар белән гариза җибәрү;

6) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәтне алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮгә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны КФҮ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин http://mfc16.tatarstan.ru/

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелә торган документациянең составы, формасы һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша яисә электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында КФҮгә, КФҮнең читтә урнашкан эш урынына язма гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6.3.2. Гаризаларны кабул итүне алып баручы КФҮ белгече, КФҮ эше регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Документлар пакетын формалаштыру

6.4.1. КФҮ белгече КФҮнең эш регламенты нигезендә:

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә кулланылган мөрәҗәгать итүченең көчәйтелгән квалификацияле цифрлы электрон имзасының дөреслеген тикшерә;

ведомствоара соратулар төзи һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрә, шул исәптән комплекслы ведомствоара сорату буенча.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: җибәрелгән соратулар.

1 нче кушымта
тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

____________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле
____________________________________
үзидарә органы исеме)

Теркәү номеры № _____ «___» _____________ 20__ел

РЕКЛАМА КОНСТРУКЦИЯСЕН УРНАШТЫРУ ҺӘМ ЭКСПЛУАТАЦИЯЛӘҮГӘ ГАРИЗА

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүченең исеме (оештыру-хокук формасы, фирма исеме; эшкуарлар өчен - Ф.И.О., паспорт мәгълүматлары) | |
| 2 | Юридик адресы | |
| 3 | Дәүләт теркәве турында таныклыкның датасы һәм номеры, ИНН | |
| 4 | Тышкы мәгълүмат чарасының фаразланган урнашу урыны | |
| 5 | Реклама (мәгълүмат) объекты тасвирламасы | |
| 6 | Кушымтада бирелгән торган эскиз материаллары исемлеге | |
| 7 | Объектны урнаштыруның таләп ителә торган срогы | |

Тышкы мәгълүмат чараларын килештерүегезне сорыйм:
____________________________________
(мәгълүмат конструкциясен, вывесканы, учреждение тактасын)
(кирәклесен ассызыкларга)

Гаризага түбәндәге сканерланган документларкушып бирелә:

2) шәхесне таныклаучы документлар;

3) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);

4) тышкы мәгълүмат чарасы (алга таба - СНИ) кушыла торган милекнең яисә мөлкәткә ия булу хокукын раслый торган документның танықланган күчермәсе;

5) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып, милекченең яки

тиешле күчемсез мөлкәтнең Россия Федерациясе ГрК 19 статьясындагы 5, 6, 7 өлешләрендә күрсәтелгән башка законлы хуҗасының әлеге мөлкәткә СНИ кушуга язмача яки электрон документ формасында ризалыгын раславы, әгәр мөрәҗәгать итүче күчемсез мөлкәтнең милекчесе яисә башка законлы хуҗасы булмаса. СНИны урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдалану кирәк булган очракта, әлеге милекчеләрнең ризалыгын раслый торган документ булып күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы шул исәптән, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрелгән җыелышы беркетмәсе тора. Әгәр мөрәҗәгать итүче мондый ризалык алуны раслый торган документны үз, дәүләт милке яисә муниципаль милке буенча тапшырмаган булса, муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә шәһәр округының җирле үзидарә органы вәкаләтле органда мондый ризалык булу турында белешмәләр соратып ала.

Әгәр дә СНИны урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдалану кирәк булса, әлеге милекчеләрнең ризалыгын раслый торган документ булып күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының беркетмәсе тора;

6) Мөрәҗәгать итүченең биләгән бинага, урынга, стационар булмаган сәүдә объектына мөлкәти хокукларын раслый торган хокук билгеләүче документлар, алар СНИны урнаштыручы оешманың, индивидуаль эшкуарның урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булып торалар (дәүләт теркәве тиеш булмаган документлар булганда).

7) Әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә җир кишәрлегенә хокук, күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрында аның теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип танылса (күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрында җир кишәрлегенә хокуклары турында белешмәләр булмаганда тапшырыла) (кирәк булганда), аерым торучы СНИ урнаштыручы оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашкан урыны (эшчәнлек башкару урыны) булган бина урнашкан җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукларын таныклаучы (билгели торган) документлар.

8) Рәсмиләштерелгән тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорт).

Сканерланган документларның төп нөсхәләрен соратып алганда тапшырырга йөкләмә алам.

_____________ ___________ _________________________________

(дата) (имза) (ФИА)

2 нче кушымта
тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

Тышкы мәгълүмат чарасының
ПАСПОРТЫ

Тышкы мәгълүмат чарасының тибы: ______________________________

__________________

Раслыйм
Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе
______________
имза Ф.И.А.
«___» ___________ 20__ ел

Тышкы мәгълүмат чарасының
Урнашкан урыны:
_________________________________

Тышкы мәгълүмат чарасын
җитештерүче:
___________________
_______________________________
_______________________________

Район архитекторы
______________
имза Ф.И.А.
«___» ___________ 20__ ел

Тышкы мәгълүмат чарасының милекчесе
___________________________________________________________________________
_________
Адресы:
___________________________________________________________________________
__________

Тел./факс ____________________ «___» ___________ 20__ ел

Тышкы мәгълүмат чарасы кушыла торган җир участогы, бина яисә башка күчемсез мөлкәт балансчысы
_________________________

_________________________
«___» ___________ 20__ ел

Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру күздә тотыла торган урынын алдан килештерү:

муниципаль берәмлек башкарма комитетының төзелеш, ТКХ, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге ________________

(_____________) «___»__________ 20__ ел;

Башка вәкаләтле органнар:

3 нче кушымта
тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

Татарстан Республикасы
______________ муниципаль
районы башкарма комитеты
җитәкчесенә
____________________нән

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
_____________________________________________________________________
(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:_________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_______________________________________________
_____________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:_______;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: _________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мине вәкилләгән затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мине вәкилләгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән. Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

______________ ________________ ( ________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)

Кушымта
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

Башкарма комитет

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе Шәйдуллин Дамир Фәрит улы | 8(84365)23050 | Damir.Shaydullin@tatar.ru |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Хәкимуллин Рамил Фатыйх улы | 8(84365)23058 | Ramil.Hakimullin@tatar.ru |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Булгаков Мурад Рамил улы | 8(84365)23055 | Murad.Bulgakov@tatar.ru |

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| «ТР Биктау муниципаль районы административ – техник инспекциясе» МКУ җитәкчесе Минһаҗев Раил Равил улы | 88436574775 | Ati.Vgora@tatar.ru |
| «ТР Биктау муниципаль районы административ – техник инспекциясе» МКУ әйдәп баручы белгече Парфенов Геннадий Анатольевич | 88436574775 | Ati.Vgora@tatar.ru |